**Казан шәһәре Башкарма комитетының**

**2026 елның 28 июлендәге 2694 номерлы карары**

**Казан шәһәренең Совет районында**
**ачык сервитут билгеләү турында**

1. Әлеге карарның 1, 2 номерлы кушымталары нигезендә ачык сервитут билгеләргә:

1.1. билгеләнә торган ачык сервитут характеристикасы:

- йогынты ясала торган өлкә мәйданы – 11984 кв.м;

- хокуклар чикләнә торган җир кишәрлекләренең кадастр номерлары: 16:16:122701:986, 16:16:122701:1051, 16:16:122701:275, 16:16:122701:509, 16:16:122701:422, 16:16:122701:278, 16:00:000000:68546;

- хокуклар чикләнә торган кадастр кварталы: 16:16:122701, 16:33:080709;

- урнашу урыны: Казан шәһәре, Совет районы;

- билгеләү максаты: газ белән тәэмин итү системасының «Җир кишәрлеге чигенә кадәр газүткәргечнең тармаклануы. Адресы: Татарстан Республикасы, Питрәч районы, Кощаково авыл җирлеге, җир кишәрлегенең кадастр номеры: 16:33:000000:4401» линия объектын төзү;

- билгеләү вакыты: 10 ел;

1.2. гариза бирүче: «Газпром трансгаз Казан» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте;

1.3. билгеләү нигезләре: гариза бирүче мөрәҗәгате; 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында»гы федераль закон; Россия Федерациясе Җир кодексының 39.37 статьясы, 23 статьясы, V.7 бүлеге 2001 елның 25 октябрендәге 137-ФЗ номерлы «Россия Федерациясе Җир кодексын гамәлгә кертү турында»гы федераль законның 3.6 статьясы, Казан шәһәре Думасының 2020 елның 28 февралендәге 5-38 номерлы карары белән расланган Казан шәһәр округының Генераль планы, Россия Федерациясе

Хөкүмәтенең 2000 елның 20 ноябрендәге 878 номерлы «Газ бүлү челтәрләрен саклау кагыйдәләрен раслау турында»гы карары, «Газпром трансгаз Казан» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте белән «А Класс Капитал» идарәче компания җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте арасында төзелгән газ куллану җиһазларын һәм капиталь төзелеш объектларын 2400-000426-25-ТП номерлы газ бүлү челтәренә тоташтыру (технологик тоташтыру) турында килешү;

2. «Казан шәһәрен үстерү институты» муниципаль бюджет учреждениесенә әлеге карарның 1, 2 номерлы кушымталары нигезендәге чикләрдә ачык сервитутның йогынты ясау өлкәсе турында тиешле мәгълүмат кертү һәм ачык сервитутны дәүләт теркәвенә алу өчен Дәүләт теркәве, кадастр һәм картография федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсенә мөрәҗәгать итүне йөкләргә.

3. Әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән ачык сервитут өчен түләү Россия Федерациясе Җир кодексының 39.46 статьясындагы 2, 3, 4, 5, 7 һәм 8 пунктлар нигезендә гамәлгә ашырыла дип билгеләргә.

4. Әлеге карарның 1 номерлы һәм 2 номерлы кушымталарында күрсәтелгән җир кишәрлекләреннән рөхсәт ителгән файдалану төре нигезендә файдалану мөмкин булмаячак яисә сизелерлек кыенлашачак вакыт 12 айны тәшкил итә дип билгеләргә.

5. Әлеге карарны, 2 номерлы кушымтасыннан кала (хезмәт урынында файдалана торган материал), «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) бастырырга, Казан шәһәре җирле үзидарә органнарының рәсми порталында (www.kzn.ru) һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

6. Әлеге карар «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) рәсми басылып чыкканнан соң гамәлгә керә дип билгеләргә.

7. «Газпром трансгаз Казан» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенә тәкъдим итәргә:

7.1. әлеге карарның 1.1 пунктчасында күрсәтелгән җир кишәрлекләренең хокук ияләре белән ачык сервитутны гамәлгә ашыру турында килешү төзергә;

7.2. әлеге карарның 1.1 пунктчасында күрсәтелгән җир кишәрлекләрен, урнаштыру өчен ачык сервитут билгеләнгән инженерлык корылмасын төзү, капиталь яки агымдагы ремонтлау, реконструкцияләү, эксплуатацияләү, консервацияләү, сүтү буенча эшләр тәмамланганнан соң яисә Россия Федерациясе Җир кодексының 39.37 статьясындагы 2, 5 пунктларда каралган


максатларда ачык сервитут билгеләнгән очракларда – җир кишәрлегендә тәэмин итү өчен ачык сервитут билгеләнгән эшчәнлек тәмамланганнан соң, өч айдан да соңга калмыйча, аларның рөхсәт ителгән файдалану төре нигезендә файдалану өчен яраклы хәлгә китерергә.

8. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Казан шәһәре Башкарма комитетының Җир һәм милек мөнәсәбәтләре комитеты рәисе Р.Г.Галәветдиновка йөкләргә.

**Җитәкче** **Р.Г.Гафаров**

Казан шәһәре
Башкарма комитетының
2026 елның 28 июлендәге
2694 номерлы карарына
1 номерлы кушымта

## Ачык сервитут йогынтысы өлкәсе чикләре




| Масштаб: 1:15000<br>Координаталар системасы: МСК-16 | |
|---|---|
| Шартлы билгеләр: | |
| 1 | Яңа ясалган характерлы нокта |
| | Ачык сервитутлар (Проектлана торган) |
| | Җир кишәрлекләре |
| 16:16:122701, 16:33:080709 | кадастр кварталлары |
| 16:16:122701:986, 16:16:122701:1051, 16:16:122701:275, 16:16:122701:509, 16:16:122701:422, 16:16:122701:278, 16:00:000000:68546 | хокуклар чикләнә торган җир кишәрлекләренең кадастр номерлары |

___________________________